ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

04.03.2021 г. Заинск №137

**«Мәҗбүри күченүчеләрне торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ буларак исәпкә кую һәм торак сатып алуга субсидияләр бирү өчен дәүләт торак сертификаты тапшыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» 2020 елның 24 мартындагы 119 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Дәүләт хезмәте һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны, «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль законны, «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 2012 елның 29 декабрендәге 2901 номерлы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарын гамәлгә ашыру йөзеннән, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. «Мәҗбүри күченүчеләрне торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ буларак исәпкә кую һәм торак сатып алуга субсидияләр бирү өчен дәүләт торак сертификаты тапшыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» 2020 елның 24 мартындагы 119 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.5 пунктның 2 баганасына түбәндәге эчтәлекле 6 нчы абзацны өстәргә:

«- чит дәүләтнең компетентлы органнары тарафыннан бирелгән граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турында таныклыклар һәм аларның нотариаль расланган рус теленә тәрҗемәсе;

- граждан хәле актларын теркәү органнары яки Россия Федерациясе консуллык учреждениеләре тарафыннан бирелгән уллыкка алу турында таныклыклар;
- мөрәҗәгать итүче үз инициативасы буенча гаилә әгъзалары буларак гаризада күрсәтелгән затлар арасында туганлык мөнәсәбәтләрен раслаучы башка документларны бирә ала».

1.2. 2.6 пунктның 2 баганасына түбәндәге эчтәлекле 3 нче абзацны өстәргә: "Граждан хәле актларын дәүләт теркәве турында таныклыклар".

1.3. 2.14 пунктның 2 нче графасына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә: Инвалидлар (кресло-коляскаларда йөрүче һәм аларны озатып йөрүче этләрне дә кертеп) тәэмин ителә:

1) социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектларына (торак, иҗтимагый һәм җитештерү биналарына, төзелмәләр һәм корылмаларга, шул исәптән физкультура-спорт оешмалары, мәдәният оешмалары һәм башка оешмалар урнашкан биналарга), ял итү урыннарына һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтләргә тоткарлыксыз керү өчен шартлар;

2) тимер юл, һава, су транспорты һәм шәһәр, шәһәр яны, шәһәрара автомобиль транспорты, элемтә һәм мәгълүмат чаралары белән тоткарлыксыз файдалану өчен шартлар (транспорт коммуникацияләре аша җәяүлеләр хәрәкәтен җайга сала торган светофорларның һәм җайланмаларның төсле тавыш сигналлары белән кабатлануын тәэмин итә торган чараларны да кертеп);

3) социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектлары урнашкан территория буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге, мондый объектларга керү һәм чыгу, транспорт чарасына утыру һәм аннан төшерү, шул исәптән кресло-коляска кулланып;

4) күз күрүе һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү функцияләренең ныклы тайпылышлары булган инвалидларны озата бару һәм аларга социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектларында ярдәм күрсәтү;

5) инвалидларның социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектларына һәм хезмәт күрсәтүләргә тоткарлыксыз керүен тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат чыганакларын аларның мөмкинлекләре чикләнүне исәпкә алып тиешенчә урнаштыру;

6) инвалидлар өчен кирәкле аваз һәм күз белән күрү мәгълүматын, шулай ук язуларны, билгеләр һәм башка текстлы һәм график мәгълүматны Брайльнең рельефлы-нокталы шрифты белән башкарылган билгеләр белән кабатлау, сурдотәрҗемәче һәм тифлосурдотәрҗемәчене аның белән бергә кертүне рөхсәт итү;

7) социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектларына инвалидны озатып йөри торган этне кертү, аның махсус укытылган булуын раслый торган, тиешле форма буенча бирелгән һәм дәүләт сәясәтен эшләү һәм гамәлгә ашыру, халыкны социаль яклау өлкәсендә норматив-хокукый җайга салу функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы билгели торган документы булганда;

8) халыкка хезмәт күрсәтүче оешмалар хезмәткәрләре тарафыннан башка затлар белән бертигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулаучы

каршылыкларны җиңүдә инвалидларга ярдәм күрсәтү.

1.4. 5.8 пунктның 1 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә».

2. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә әлеге карарны Зәй муниципаль районының http://zainsk.tatarstan.ru рәсми сайтында һәмТатарстан Республикасы хокукый мәгълүматының http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **Э.Э.Галеев**

С.А.Филюшина
7 07 75
Юрист